ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
"АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ "
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«АКСУБАЕВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКИЯЗЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**423073, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район, село Старые Киязлы, ул. Центральная д.57**

**Тел. (8-84344-4-30-39) ОГРН 1061665002332,
ОКПО 94318671, ИНН/КПП 1603004832/160301001**

---

КАРАР

№16 2021 ел, 20 декабрь

«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 18.07.2014 ел, №10 карарына үзгәрешләр кертү хакында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31, 32, 33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының «Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясендә ачык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 27.04.2018 ел, № 63 карары нигезендә, Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегендә җир берәмлегенең җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы таләпләренә туры китерү максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Аксубай муниципаль районы «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проектны ачык тыңлауларга чыгарырга.
2. Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы, Иске Кыязлы авылы, Үзәк урам, 57 нче йорт(җирле үзидарә)адресы буенча мәгълүмат стендында ачык тыңлаулар үткәрү турында хәбәрне элү юлы белән халыкка игълан итәргә:
- Аксубай муниципаль районы «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү һәм гражданнарның аның турында фикер алышуда катнашуы проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе (1 нче кушымта);
- Аксубай муниципаль районы «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект (2 нче кушымта);

3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы» Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проекты буенча 2022 елның 25 гыйнварына 14.00 сәгатьтә Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы, Иске Кыязлы авылы, Үзәк урам, 57 нче йорт(җирле үзидарә) адресы буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

4. Кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә (3 нче кушымта).

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Аксубай муниципаль районының http:// aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Г.Дәүләтшин

Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгының
20.12. 2021 ел, №16
карарына 1 нче кушымта

Ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе

1. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар 423073, Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы, Иске Кыязлы авылы, Үзәк урам, 57 нче йорт(җирле үзидарә) адресы буенча, шәхсән яки почта аша тапшырыла.

2. Ачык тыңлауларда катнашучылар, үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән, ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр язмача гаризалар биргән җирлек халкы катнаша.

3. Чыгыш ясау хокукыннан башка ачык тыңлауларында җирлекнең барлык кызыксынган кешеләре катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 30 минут алдан башлана.

5. Ачык тыңлауларда җирлек башлыгы рәислек итә. Ачык тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул утырышта катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

6. Ачык тыңлауларда катнашучылар, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

7. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

8. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

9. Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

10. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

11. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре ачык тыңлаулар беркетмәсенә кертелә. Беркетмә җирлек Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

12. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә эшче төркем тарафыннан әзерләнә һәм халыкка җиткерелергә тиеш.

Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгының
20.12. 2021 ел, №10
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 18.07.2014 ел, № 10 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 31,33 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законга, Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына тапшыру, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру турындагы 29.11.2021 елдагы Килешүгә таянып, Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләрдән файдалану һәм төзү кагыйдәләрен раслау турында» 18.07.2014 ел, №10 карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. «Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары» җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең 35 һәм 11 статьяларына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

Җир кишәрлекләренең чик күләме һәм рөхсәт ителгән төзелеш,
капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрлары

| | | Кучемсез мөлкәтне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның әһәмияте | |
|---|---|---|---|
| | | Аерым торучы гаилә йорты | Бер гаиләгә исәпләнгән торак берәмлек күп блокланган гаиләләр йортта |
| Җир кишәрлекләренең чик параметрлары | | | |
| Минималь мәйдан | Кв.м | | 1000 |
| Урам фронты буенча минималь киңлеге (юл) | м | | 5 |
| Участок чикләрендә төзелешнең рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары. Участокның төзелеш алып бару максималь проценты | % | 45 | 55 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Участокның алгы чигеннән минималь чигеннән чигенү (башка күрсәткеч төзелешне җайга салу сызыгы белән билгеләнмәгән очракта) | м | 3 | 3 |
| Корылмаларның участок чикләре яннарыннан минималь чигенүләре | м | а) 1- брандмауэрлы дивары мәҗбүри булганда,; б) 5- бүтән очракларда | а) 0- күрше блокларга кушылган очракларда; б) 3- бүтән очракларда |
| Участокның арткы чигеннән минималь чигенү. | м | 3 | 3 (әгәр башкасы төзелешне җайга салу линиясе белән билгеләнмәгән булса.) |
| Корылмаларның максималь биеклеге | м | 12 | 12 |
| Җир кишәрлекләре киртәләренең максималь биеклеге | м | 2,5 | 2,5 |

Бакчалар биләп торган өлешендә чиктәш участоклар арасындагы киртәләрнең материалы һәм тибы яктырткычларны үткәрүче челтәрле кабул ителә.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, индивидуаль торак төзелеше, гаражлар төзү һәм урнаштыру, хуҗалык корылмалары төзү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләме түбәнрәк китерелгән таблицадан күрсәткечләргә туры килергә тиеш.

| Үлчәү берәмлекләре һәм параметрлары төрләре | | Күчемсез милекне куллануның ярдәмче һәм шартлы рәхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның әһәмияте | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Бакчалар, яшелче бакчалар. (ЛПХ) | Индивидуаль торак төзелеше | Индивидуаль гаражлар | Хуҗалык корылмалары |
| Җир кишәрлекләренең чик параметрлары | | | | | |
| Минималь мәйдан | кв.м. | 1000 | 1000 | 30 | 30 |
| Максималь мәйдан | кв.м. | 5000 | 2500 | 100 | 100 |

1.2. Гражданнарның фактта файдалануында булган яисә әлеге карар үз көченә кергәнче билгеләнгән тәртиптә бирелгән җир участогының күләме иң чик минималь күләмнән кимрәк

яисә әлеге карарда каралган иң чик максималь күләмнән артып киткән очракта, әлеге җир участогы өчен аның күләме минималь яки максималь чик күләмнән артып китә.

1.3. Гражданнарның даими (срoксыз) файдалану яки гомерлек мирас итеп алу хокукындагы җир кишәрлекләренә карата җир кишәрлекләренең чик күләмнәре кулланылмый.

1.4. Әлеге карарның 3 пункты нигезендә бирелә торган җир кишәрлекләре мәйданын төгәлләгәндә чыгым 10% тан да артмаска мөмкин.

1.5. Түбәндәге кишәрлекнең нормадан артык өлеше мөстәкыйль җир кишәрлеге буларак төзелергә һәм кызыксынган катнаш җир кулланучыларын килештерү шарты белән төзелгән очракта, максималь күләмнәрдән артыграк булган җир кишәрлекләре иң чик күләмнәрдән искәрмә булып тора.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Аксубай муниципаль районының http:// aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында, Иске Кыязлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске кыязлы авыл җирлегенең экология һәм төзекләндерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Г.Дәүләтшин

Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгының
20.12.2021 ел, № 16
карарына 3 нче кушымта

**Кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү**
**һәм карау буенча эшче төркем составы**

| | |
|---|---|
| Дәүләтшин Г.Г. | - комиссия рәисе, Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы |
| Ислямов И.И. | - Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Габдрахманов М.А. | Аксубай муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Сәхәбетдинова Л. С. | – Росреестр Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Аксубай, Яңа Чишмә һәм Чирмешән районнарында муниципальара бүлек башлыгы |
| Гиматова Г.Ә. | – комиссия секретаре, Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |